*Муниципаль тур*

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен**
**татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**4 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

## I. ТЕСТ (18 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **4** | **3** | **2** | **1** | **2** | **3** | **1** | **1** | **1** |

## II. Теоретик бирем.

Шигырьне укыгыз. Берлек сандагы 1 һәм 2 зат алмашлыкларын тиешле килештә куеп, сүзләр белән языгыз. Зат алмашлыклары турында белгәннәрегезне языгыз. **(10 балл) 4+6**

**Синдә** җыр бар,
**Миндә** җыр бар –
Матур җырлар бик күп җирдә.
Синең җырың миңа күчсен,
**Минем** җырым **сиңа** күчсен –
Җырлыйк әле бергә-бергә (Ф. Яруллин).

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, биремгә иң югары балл **(6)** куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) хәрәкәткә килү | 1) шәп белү |
| Ә) ут борчасы | 2) хәрәкәтчән |
| Б) су кебек эчү | 3) югалту |
| В) колак кагу | 4) ягымлы |
| Г) тәмле телле | 5) кузгалу |

**Җавап : 52134**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. (**4 балл**)

М**е**нә ике көн инде
Үзем җыештырам өйне.
Буямагыз, белегез,
Бик сакланып **йөрегез**.

Җил чыкса, тузан керер,
Ф**о**рточканы ачмагыз.
Үзем җы**е**штырдым өйне,
Чисталыкны саклагыз!

(Заһирә Гомәрова)

2. Шигырьнең икенче куплетыннан басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз (**2 балл**)
**ачмагыз, саклагыз**
3. *Җил* сүзенә 4 тамырдаш сүз уйлап языгыз. (**4 балл)**
җилле, җилсез, җиллә(ү), җиләс
4. “Чисталыкны саклыйк!” темасына 6-7 җөмләдән торган инша языгыз. **(7 балл)**

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**5 нче сыйныф**

**Максималь балл – 58**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **4** | **3** | **2** | **3** | **3** | **3** | **2** | **3** |

## II. Теоретик бирем.

Шигырьне укыгыз. Аерып бирелгән 1 зат берлек сандагы фигыльләрнең тиешле кушымчаларын языгыз. Хикәя фигыль турында белгәннәрегезне языгыз. (**10 балл**) **4+ 6**

Фәннәр **укый**м мәктәбемдә –
Тырышып белем **алам**.
Туган телемне яратам,
Тукайны укып **беләм**.
Беләсегез килсә, быел
Мин бишенчегә керәм.
Алдымда күпме мәсьәлә
Җавабын үзем чишәм.
Йолдызлар серен ачарга
**Чакыра** мине җиһан.

Укучы хикәя фигыль турында мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, биремгә иң югары балл **(6)** куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III.Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Бирелгән сүзләргә берәр хәреф өстәп, тамырдаш сүз ясагыз, ул сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

Тара- - тарак
Бизә- - бизәк
Аш - аша
Илә- иләк
Ела- - елак

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) трай тибү | 1) ачулану |
| Ә) авызы колакка җитү | 2) эшләмәү |
| Б) пыр туздыру | 3) курку |
| В) күз буяу | 4) алдау |
| Г) хафага төшү | 5) шатлану |

**Җавап : ______25143_________________**

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Алланып таңнарның алына,
Нур булып кешелек таңына,
Җыр булып үрелеп кү**ң**елгә,
Кил безгә, Яңа ел, кил безгә!
Ко**я**шлы көннәрнең җылысын,
Бәхетнең, шатлыкның ол**ы**сын
Күтәреп көннәрнең и**ң**енә,
Рәхим ит Туган ил түренә! (*Э. Мөэминова*)

3. *Кояшлы көннәрнең җылысын* юлындагы сүзләрне антонимнарына үзгәртеп языгыз. **(3 балл)**

**Болытлы төннәрнең салкынын**

---

4. Беренче куплеттан тамырдаш сүзләрне күчереп алыгыз, сүзләрнең тамырын шартлы билге белән күрсәтегез. **(3 балл)**

**Алланып, алына, ал - тамыр**

5. “Нәрсә ул матурлык?” темасына 7-8 җөмләдән торган инша языгыз. (**8 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 57**

**I. ТЕСТ (20 балл)**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **3** | **2** | **4** | **1** | **3** | **2** | **3** | **3** | **4** | **3** |

**II. Теоретик бирем.**

Шигырьне укыгыз. Аерып бирелгән исемнәрнең тиешле кушымчаларын языгыз. Исемнең килеш белән төрләнеше турында белгәннәрегезне языгыз. (**10 балл**) **5+ 5**

Мин **бәхетне** кайдан алырмын,
Туган **йорттан** китсәм **гомергә**?
Таш булып мин җансыз калырмын,
Сүз югалыр минем **телемдә**.
Бер көн артык миңа мең **елдан**,
Айда түгел, туган илемдә! (*Н. Дәүли*)

Укучы исемнең килеш белән төрләнеше турында мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл **(5)** куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

**III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.**

Сүз ясалыш чылбырында төшеп калган сүзне языгыз. **(5 балл)**
Яшел **–** ___ **яшелчә** ___, яшелчәче
Өмет **–** ___ **өметсез** ___, өметсезлек
Аш **–**___ **ашла** ___, ашлама
Сабыр **–** ___ **сабырсыз** ____, сабырсызлык
Бүл **–**___ **бүлмә** ___, бүлмәдәш

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

11. Сүз һәм аның килеп чыгышы ягыннан төркемчәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) дизель | 1) рус алынмасы |
| Ә) салам | 2) төрки-татар сүзе |
| Б) абый | 3) фарсы алынмасы |
| В) мәдрәсә | 4) гарәп алынмасы |
| Г) җиһан | 5) Европа алынмасы |

**Җавап : 51243**

2. Шигырьне укыгыз һәм күп ноктлар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) һәр төшеп калган хәреф – 0,5 балл**

Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кичтә!
Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;
Утырасыз рәхәтләнеп, т**е**зелешеп,—
Шатлык сезгә, уңайсызлык килми **һ**ич тә.
Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,
Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең оз**ы**нлыгын сизмисез дә
Ә**н**кәгезнең сөйләгәне әкият берлә. (*Г. Тукай*)

3. Шигырьдән антоним сүзләрне күчереп алыгыз, сүз төркемнәрен күрсәтегез. **(3 балл)**
**шатлык – хәсрәт. Исем сүз төркеменә карый**

5.*Берлә* сүзенең хәзерге татар телендәге сүзен языгыз. **(2 балл)**
**белән**

6. “Кышкы кич” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 64**

**I. ТЕСТ (20 балл)**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **3** | **2** | **3** | **3** | **2** | **3** | **3** | **3** | **1** | **1** |

**II. Теоретик бирем.**

Искергән сүзләр турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**8 балл**)

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары **балл (8)** куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

**III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.**

Мәкальләрнең ахырын уйлап языгыз. **(5 балл)**

1. *Өең кысан булса да,* күңелең иркен булсын.
2. *Яхшы тел* – җан азыгы.
3. *Сөйдергән дә – тел,* биздергән дә –тел.
4. *Баканың да* үз тавышы үзенә матур.
5. *Өйрәнгән* җирдә калмас.

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Тексттагы <... > тамгасы урынына тиешле тыныш билгеләрен куегыз. **(7 балл)**

Март ахыры якынлашкач <,> беренче зур яңалык шул булды <:> кычыткан күбәләге оча башлады. Кирпеч төсле кызыл күбәләк. Шул кызыл өстендә вак кара таплар күренә. Юка канатлары читеннән кара кайма киткән <,> ә каймага зәңгәр таплар тезелгән. Күбәләк суыкны агач ярыгында уздырган һәм яз җиткәч уянган.

Бераздан үрмәкүчләр уянды <,> кайберләре кар өстендә сәяхәт итә башлады. Иртән кояш күренә <-> үрмәкүч терелә <,> кичен суыта <-> ул тагы үлеп куя. *(Г. Хәсәнов*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп ноктелар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) һәр төшеп калган хәреф – 0,5 балл**

Татлы тәм бар ипекәйдә.
Төш**е**ндем мин яши-яши:
Кеше аңа үз ө**е**ндә
Сөенечен кушып ашый.
Ачы тәм бар ипекәйдә.
Карусыз гом**е**р юлдашы:
Шуның өчен аңа кеше
Көенечен кушып ашый. (*Р. Зәйдулла*)

3. *Ачы тәм бар ипекәйдә.* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. (**4 балл**) **тәм – ия, бар – хәбәр, ачы – аергыч, ипекәйдә- кыек тәмамлык. Бу –җәенке ике составлы гади җөмлә**

4. Шигырьдән антоним парларны күчереп языгыз, сүзләрнең кайсы сүз төркемнәренә каравын билгеләгез. (**4 балл**) 2+**2**

**татлы – ачы - сыйфат, сөенеч – көенеч - исем**

5. Шигырьдән үткән заман хикәя фигыльне табып языгыз, морфологик анализ ясагыз. **(3 балл) төшендем – тамыр, билгеле үткән заман хикәя фигыль, 1 нче зат, берлек санда, барлыкта**

6. Сөйләм теленә хас сүзне күчереп алыгыз. **(2 балл)**

**ипекәй**

7. “Икмәк кадере” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**9 балл**)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен**
**татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 60**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **3** | **2** | **4** | **3** | **1** | **4** | **3** | **2** | **4** | **рәвеш** |

**II. Теоретик бирем.**

Сузык авазлар өлкәсендә очрый торган аваз үзгәрешләре турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**8 балл**)

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Сүз һәм андагы басымның урынын тәңгәллек белән күрсәтегез**,** җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| СҮЗ | БАСЫМ УРЫНЫ |
|---|---|
| А) пәрәмәч | 1) икенче иҗектә |
| Ә) бирешмәскә | 2) өченче иҗектә |
| Б) кайчаннан | 3) беренче иҗектә |
| В) кырмыскалар | 4) дүртенче иҗектә |
| Г) чишелешендә | 5) бишенче иҗек |

**Җавап : 21345**

## IV. Гамәли-иҗади бирем

1. Мәкальләрнең ахырын уйлап языгыз. **(5 балл)**
   *Егет сүзе* бер булыр.
   *Бер – алдыңа,* биш артыңа кара.
   *Аз сөйлә, күп эшлә.*
   *Җиде кат үлчә,* бер кат кис.
   *Туры әйткән – котылган,* ялганлаган – тотылган.
2. Текстны укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) һәр төшеп калган хәреф – 0,5 балл**

Мин үзем икмәкне кеше өчен иң зарури ризык итеп кенә түгел, ә илнең иң зур байлыгы, дәүләтнең төп к**у**әте дип тә саныйм. Чыннан да, илдә, дәүләт кулында икмәк җитәрлек булмаса, халык тук, бөтен яши алыр идемени, дәүләт башка байлыкларын бүтән ихт**ы**яҗларга тота алыр идемени?..

Халык икмәкнең дәрәҗәсен кытлык елларда гына түгел, **һ**әрвакытта, иң уңган чакларында да бик яхшы белгән. Ул аны юкка-барга әрәм-шәрәм итмәгән, саклап тоткан, ничек тә запас белән торырга тырышкан. Безнең татар халкында исә икмәккә хөрмәт аеруча зур иде. “Ипекәй” дип к**а**дерләп кенә йөртә иде ул аны... (*Әмирхан Еникидән*)

3. Текстта антонимик парлы сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)
**юкка-барга**

4. *Байлыкларын* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**4 балл**)
бай – тамыр, -лык – исем ясагыч кушымча, -лар – күплек сан кушымчасы, модаль, -ын –3 нче зат төшем килеше кушымчасы, бәйләгеч. Байлыкларын – ясалма исем, уртаклык исем, төшем килешендә, 3 зат тартым белән төрләнгән, күплек санда.
5. *“Ипекәй” дип кадерләп кенә йөртә иде ул аны*... җөмләсендәге сүзләрне туры тәртипкә куеп языгыз. **(2 балл)**
Ул аны “ипекәй” дип кадерләп кенә йөртә иде.
6. Тексттан рус алынмасын күчереп языгыз. **(2 балл)**
**запас**
7. *“Азның кадерен белмәгән күпнең кадерен белмәс”* темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ 2025-2026 нчы уку елы 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл –66**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2** | **1** | **4** | **4** | **4** | **2** | **1** | **3** | сызык | мәсьәләне |

**III. Теоретик бирем.**

Тартыклар охшашлануы турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(8 балл)** Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фигыльләр һәм аларның төркемчәләрен тәңгәллек белән күрсәтегез**,** җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| ФИГЫЛЬ | ТӨРКЕМЧӘСЕ |
|---|---|
| А) соңлаган яз | 1) исем фигыль |
| Ә) урындыкка утыру | 2) хәл фигыль |
| Б) уйлар таралгач | 3) хикәя фигыль |
| В) куелмаган иде | 4) сыйфат фигыль |
| Г) әйткән булса | 5) шарт фигыль |

**Җавап : 41235**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Фразеологик әйтелмә барлыкка килерлек итеп, фигыльләр өстәп языгыз. **(5 балл)**

Борчак **сибү/аттыру**
Кызыл кар **яугач**
Балтасы суга **төшү**
Трай **тибү**
Тетмәсен **тетү**

2. Тексттны укыгыз һәм <...> тамгасы урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) һәр төшеп калган хәреф – 0,5 балл**

1) Авылның үзенә генә хас тавышлар белән тулган изге тынлыгын бернинди бөек симфонияләр, моңлы көйләр дә уза алмый. 2) Бөтенесе йөрәккә якын, бөтенесе якты нур белән, ила <**һ**>и тынлык, куанычлы моң белән өр<**е**>телгән. 3) Шуңа күрә авыл кешесенең шатлык-куанычлары да мәңге онытылмаслык, борчу-газаплары да йөрәген сулкылдатырлык тирән. 4) Әгәр шулай булмаса, авылыннан китеп, чит-ят җирләрдә гомер кичерүче кешеләр аны хәтерләреннән жуяр иде. 5) Юк шул, онытa алмый <**а**>дәм баласы туган төбәген. 6) Аның хәтерендә ялан тәпи баскан чирәмле ишегалды, аунап-тәгәрәп үскән болыннары, су кое<**н**>ган күлләре, челтерәп аккан чишмә суларының тәмнәре, җиләк-җимеш тулы әрәмәләре, ап-ак кышлары торган саен жетерәк, дулкынландыргычрак булып яңара. (*Ф. Садриев*)

3. Тексттан Европа алынмасын табып, күчереп языгыз. **(2 балл)**
**симфонияләр**
4. Тексттан синонимик парлы сүзләрне күчереп языгыз, кайсы сүз төркеменә карауларын билгеләгез. **(4 балл)**
**шатлык-куанычлары – исем , борчу-газаплары - исем, чит-ят - сыйфат, аунап-тәгәрәп - фигыль**
5. 5-6 нчы җөмләләрдән әдәби нормадан читләшкән сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)
**дулкынландыргычрак**
6. Тексттан *тын* сүзенә тамырдаш сүзне табыгыз, үзегез тагын ике тамырдаш сүз уйлап языгыз. (**3 балл**)
**тын – тынлык - тыныч - тынычлану**
7. Бишенче җөмләне туры тәртипкә үзгәртеп языгыз. **(5 балл)**
**Юк шул, адәм баласы туган төбәген оныта алмый.**
8.“*Авылым иртәсе*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**10 нчы сыйныф**

**Максималь балл –63**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **4** | **4** | **3** | **1** | **3** | **1** | **2** | **2** | **өтер** | **үз** |

**II. Теоретик бирем.**

Татар теленең орфографик принциплары турында языгыз, мисаллар китерегез. **(8 балл)**

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны кимителә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Синоним сүзләрне үзара тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) шыту | 1) җай |
| Б) тойгы | 2) гамьсез |
| В) форсат | 3) җан |
| Г) кот | 4) хис |
| Д) ваемсыз | 5) тишелү |

**Җавап : 54132**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Бирелгән сүзләрнең тамырын языгыз. **(5 балл)**

Җәмәгатьчелек –**җәмәгать**
Сырганак –**сыр(у)**
Караңгы –**кара**
Тартма –**тарт(у)**
Аңлаешлы –**аң**

2. Шигырьне укыгыз һәм күп ноктала урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(1 балл) һәр җавапка – 0,5 балл**

Ниләр диеп мин аңлатыйм икән
Шушы сәер, иләс чагымны?
Хәреф төртсәң, шигыр**ь** үсеп чыгар -
Шундый чагы әле җанымның...
Вето салдым барлык мескенлеккә!
Җитте! Оят ап-ак бол**ы**ттан!
Яшәү дигән тантанага бит без
Вакытлыча гына юлыккан... (*Зөлфәт*)

3. *Вето* сүзенең татар телендә кулланыла торган ике синонимын языгыз. **(2 балл)**
**тыю, рөхсәт итмәү, тоткарлау ....**

4. *Иләс* сүзенең мәгънәсен аңлатып языгыз. (**3 балл**)
**Иләс – ашкынучан, җилкенүчән, шашкын, ярсулы.**

5. *Мескенлеккә* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

Мескен – тамыр, -лек – исем ясагыч кушымча, -кә – бәйләгеч, юнәлеш килеше кушымчасы.
Мескенлеккә (салдым) – ясалма, уртаклык исем, юнәлеш килешендә, берлек санда, тартымсыз.

6. Шигырьдәге *юлыккан* сүзенең транскрипциясен языгыз, фонетик анализ ясагыз. **(2 балл)**
[йулыкқан]
7 хәреф, 8 аваз. 3 иҗектән тора. Сузык авазлар: [у], [ы], [а]. Тартык авазлар: [й], [л], [к], [к], [н].
[у] – арткы рәт, югары күтәрелешле, иренләшкән озын сузык аваз.
[ы] - арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән кыска сузык.
[а'] – арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән озын сузык аваз.
й] – сонор, парсыз, тел уртасы, өрелмәле, авыз тартыгы.
[л] - сонор, парсыз, тел алды (тел-теш), ярымйомык, авыз тартыгы.
[к] – кече тел, йомык, парлы, саңгырау тартык.
[н] – сонор, парсыз,тел алды яңгырау тартык .
7. Шигырьдән артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны күчереп языгыз. **(2 балл)**
**ап-ак**

8.“ *Игелекле эш*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 67**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2** | **2** | **1** | **2** | **4** | **1** | **3** | **2** | авырлыклар | максат хәле |

**II. Теоретик бирем.**
Тезмә кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. **(8 балл)**
Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологизмнар һәм аларның мәгънәләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) ата йорты | 1) ял итеп алу |
| Ә) бәлеш авыз | 2) үч саклау |
| Б) баш кую | 3) хәтере тиз калучан кеше |
| В) үпкә бәлеше | 4) елак бала |
| Г) кинә тоту | 5) ватан |

**Җавап: 54132**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Бирелгән сүзләрнең тамырын билгеләп языгыз. **(5 балл)**
Безелдәвек – **без**
Тузганак – **туз(у)**
Киселмәле – **кис(ү)**
Кадак – **када(у)**
Аңлаешсызлык – **аң**

2. Шигырьне укыгыз һәм күп ноктала урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(1 балл) һәр хәрефкә 0,5 балл**
«Сул аягың җиргә ныклап терә,
Чыбыркыңны уң кулыңа, ипләп…»
Көтүлектә шартлый кыюсыз чаң,
Г**а**ләм хәтеренә аваз киртләп.
Тагын, тагын… Елан тәсл**е** ыслап,
Чыелдатып шартлый чыбыркым ла.
Мин җәйләүдә. Мин көтүче бүген.
Әткәм чыбыркысы <....> минем кулда! (*Л. Гыйбадуллинадан*)

3. *Әткәм чыбыркысы* <-> *минем кулда!* җөмләсендә <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**
**сызык**
4. Шигырьдән аваз ияртемнәреннән ясалган сүзләрне күчереп языгыз, сүз төркемен һәм төркемчәсен билгеләгез. (**3 балл**)
**шартлый – хәзерге заман хикәя фигыль, ыслап, чыелдатып – 1 төр хәл фигыль**
5. Беренче дүртьюллыктан тартымлы исемнәрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)
Аягың: аяк – тамыр, -ың – бәйләгеч кушымча. Аягың – тамыр, уртаклык исем, баш килештә, 2 зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
Чыбыркыңны: чыбыркы – тамыр, -ың – бәйләгеч кушымча, -ны – бәйләгеч кушымча. Чыбыркыңны – тамыр, уртаклык исем,төшем килешендә, 2 зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
Кулыңа: кул – тамыр, -ың – бәйләгеч, -а бәйләгеч кушымча. Кулыңа - тамыр, уртаклык исем, юнәлеш килешендә, 2 зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
Хәтеренә: хәтер – тамыр, -е -бәйләгеч, -нә – бәйләгеч кушымча. Хәтеренә - тамыр, уртаклык исем, юнәлеш килешендә, 3 зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
6. *Галәм хәтеренә аваз киртләп* җөмләсендәге *киртләп* сүзен ничек аңлыйсыз? Үз сүзләрегез белән аңлатып языгыз. **(3 балл)**
**киртләп – искәртеп, хәтергә төшереп, кисәтеп**
7. *Елан төсле ыслап,Чыелдатып шартлый чыбыркым ла.* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. **(5 балл)**
Бу – ике составлы җәенке, тулы хикәя җөмлә. Чыбыркым – ия, шартлый – хәбәр, елан төсле (ыслап) – рәвеш хәле; ыслап, чыелдатып –тиңдәш рәвеш хәлләре.
8.“*Авылым хәтирәләре*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)